| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОЛГАР ШӘҺӘРЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |
| **КАРАР** | **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** |
| № 66 | «06» 09 2022 ел |

Болгар шәһәр Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 19 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2022 елның 31 маендагы прокурорның протестын карап, Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Болгар шәһәр Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 19 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.10 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган тәкъдимнәрдә катнашучы оешмалар һәм Вәкаләтле экспертлар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә торган хезмәтләр исемлеге.

1.2. Административ регламентны түбәндәге эчтәлекле 3.4.1 бүлек белән тулыландырырга:

«3.4.1. Муниципаль хезмәтне алдан ук (актив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Костина